| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от** 24.07.2024 г. Казань 582/2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмат алмашу регламентын раслау турында» 16.12.2014 ел, № 405 боерыгын көчен югалткан дип тану турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, «Электр энергиясен (куәтен) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең электр энергиясен (куәтен) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 22 июлендәге 614 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 24.07.2024 ел, № 16-пр утырыш беркетмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмат алмашу регламентын раслау турында» 16.12.2014 ел, № 405 боерыгын көчен югалткан дип танырга.

2. Бу боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина